**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**“АЕРЫМ ПРЕДМЕТЛАР ТИРӘНТЕН ӨЙРӘНЕЛӘ ТОРГАН**
**2НЧЕ АЛЕКСЕЕВСК УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ”**
**МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ ГОМУМИ БЕЛЕМ УЧРЕЖДЕНИЯСЕ**

| **«КАРАЛДЫ»** | **«КИЛЕШЕНДЕ»** | **«РАСЛАНДЫ»** |
|---|---|---|
| Методик берләшмә житәкчесе<br>___________Замалиева И.Х.<br>МБ утырышы беркетмәсе<br>№1 25 август 2016 ел | Директор урынбасары<br>_______Л.Р.Ягудина<br><br>27 август 2016 ел | Мәктәп директоры<br>__________Л.Н.Липлянина<br>Педагогик совет беркетмәсе<br>233 нче номерлы боерык белән гамәлгә кертелде.<br>31 август 2016 ел |

Татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Чибинова Лилия Рәис кызы
5 «б» сыйныфы өчен әдәбияттан
эш программасы

Педагогик киңәшмә
Утырышында каралды.
Беркетмә №1
31 август 2016 ел

**2016 - 2017**

## <u>Укыту предметын үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре.</u>

**Сыйныф**: 5 б
**Укытучы:** Чибинова Л.Р..
**Уку планы буенча <u>татар әдәбиятыннан</u>:***70 сәг.*
**Атнага:***2сәг.*
Тест :4
Проект эше:4
Административ тест:1
**Дәреслек -** Мотыйгуллина Ә.Р. Ханнанов Р.Г.,Хисмәтова Л.К.”Татар әдәбияты”.Рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек.5нче сыйныф.2кисәктә.Казан, “Мәгариф-Вакыт” нәшрияты, 2014ел.

Программа түбәндәге документлар нигезендә төзелде:

1.Программа: Татарстан РеспубликасыМәгарифһәмфәнминистрлыгы. Урта (тулы) гомумибелембирүмәктәбендәрустелле балаларга татар теленкоммуникатив технология нигезендәукытупрограммасы (1 — 11 нчесыйныфлар). Төзүче – авторлары: Р.З. Хәйдәрова, Р. Л. Малафеева, 2014 ел.
2Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомумибелемучреждениясе “Аерымпредметларнытирәнтенөйрәнүче Алексеевск 2 нчеуртагомумибелембирүмәктәбе”нең төп гомуми белем бирү баскычындабашлангычгомумибелембирүпрограммасы.
3.Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомумибелемучреждениясе “Аерымпредметларнытирәнтенөйрәнүче Алексеевск 2 нчеуртагомумибелеммәктәбе”нең 2016-2017укуелынаукытупланы (№1 педсовет протоколы, 31 август 2016 ел).
Татар әдәбиятыннан 5 нче сыйныф укучылары өчен төзелгән программа дәүләт стандартларының федераль компонентына, гомуми белем бирү федераль дәүләт стандартларына нигезләнеп эшләнгән Ә.Р.Мотыйгуллина, Р.Г.Ханнанов, Л.К.Хисматова, Э.Х.Гыйзәтуллина, Г.Г.Мулласалихова тарафыннан язылган дәреслекләрдән (1 нче, 2 нче кисәк) укытуны күздә тота. Программа стандартның эчтәлеген җентекләп ачып бирә, стандарт таләп иткән күләмдә рус телле балаларга татар әдәбиятын укытуның гомуми юнәлешләрен билгели, предмет чаралары белән укучыларны тәрбияләү юлларын, аларның әдәби үсеш дәрәҗәсен билгели.

Күпмилләтле аудиториядә татар әдәбиятын укыту өчен төзелгән программа бербөтен документ булып тора, ул биш өлешне иңли: аңлатма язуы; укыту курсының эчтәлеге, укыту-тематик планы; укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр; курсның укыту-методик тәэмин ителеше өчен әдәбият исемлеге.

Әдәбият һәр яктан үскән, рухи яктан бай, әхлакый идеаллары һәм эстетик таләпләре булган камил шәхес тәрбияләү әһәмиятле урын алып тора. Урта белем бирү системасындагы татар әдәбияты курсы сәнгатьне тормыш белән бәйләп өйрәнүгә, эчтәлек белән форма берлеге, тарихилык, традиция һәм новаторлык, тарихи-культурологик мәгълүматларны аңлау, әхлакый-эстетик күзаллау булдыру, әдәбият теориясе һәм тарихы буенча төшенчәне үзләштерү, әдәби әсәрне бәяләү һәм күнекмәләрне формалаштыру, әдәби телнең сәнгатьлелек чараларын үзләштерү.

Федераль дәүләт стандартларына нигезләнеп төзелгән татар әдәбияты дәреслекләре барлык фәннәрне өйрәнү барышындагы фундаменталь төшкә (фундаментальное ядрога), универсаль уку гамәлләренә нигезләнә, укучыларның яшь һәм әдәби үсеш дәрәҗәсен исәпкә ала. Укыту һәм тәрбиянең гомуми нәтиҗәләре иҗтимагый, шәхси, танып-белү һәм коммуникатив үсешне тәэмин итеп, укучыларның белемнәрен, күнекмәләрен үстереп, дөньяны танып белүгә әзерләп, хезмәттәшлеккә, үзлегеннән белем алуга, камиллеккә омтылучы шәхес тәрбияләүгә барып тоташа. Аерым алганда, уку-укытуга системалы-гамәли якын килү нәтиҗәсендә, укучыларның иҗтимагый үсешенә (халыкның рухи кыйммәтләрен аңлаучы, үстерүче Россия гражданины тәрбияләү); шәхси үсешенә (үзлегеннән белем алырга, иҗади сәләте үскән, компетентлы, үзаңы үскән, үзенең гражданлык карашларын ачыктан-ачык белдерүгә сәләтле, үз-үзенә тәнкыйди караштa торган, тормыш авырлыкларын каршы торырлык шәхес тәрбияләү); танып белү эшчәнлеген үстерүгә (фәнни дөнья сурәтен аңлаучы, үзенең танып-белү һәм интеллектуаль эшчәнлеге белән идарә итә ала торган, уку, белем алу чараларын күзаллый торган, репрезентатив, символик, логик, иҗади фикерләү сәләте үскән, рефлексиягә сәләтле укучы тәрбияләү); коммуникатив үсешкә (аралашу компетенциясе үскән, тыңларга, диалогта, гомуми сөйләшүдә катнаша алырлык, туган телен, рус телен, чит телне камил белүенә) басым ясалды. Шул ук гамәлләрне тормышка ашыру барышында, яшүсмерләрнең яшь үзенчәлекләре дә игътибарга алынды.

Күпмилләтле мохиттә гомуми әдәби белем бирү барышында универсаль уку гамәлләре дүрт блокка бүлеп каралды. Алар арасында шәхси УУГ − тормышчан, шәхескә юнәлтелгән, һөнәри юнәлештә үз юлын табуга, кешенең эчке потенциалын рациональ файдалана белүенә бәйле блок. Регулятив уку гамәлләре шәхес тәрбияләүдә планлаштырырга өйрәтү, фаразлау, коррекция, бәяләү кебек якларны үзәккә ала. Танып белү гамәлен алгы планга чыгарган блокта логик, проблеманы кую һәм чишүгә юнәлтелгән, тамга-символик якны иңләгән гомумуку гамәлләренә игътибар ителә. Коммуникатив УУГ кешеләр язмышына битараф булмауны, кешеләргә ярдәмчеллек сыйфатларын тәрбияләүне, иҗтимагый компетентлыкны үз эченә ала.

Универсаль уку гамәлләрен рус телле балаларга татар әдәбиятын укыту барышында куллану нәтиҗәсендә, укучыларны мөстәкыйль эшләргә өйрәтү юнәлеше көчәйде (мәсәлән: өй эше бирү − берничә вариантта). Бу вакытта укытучы эшчәнлегендә идарә итү алымнары көчәя.

Шул рәвешле, федераль дәүләт стандартларына таянып татар әдәбиятын өйрәнүнең **максаты** да ачыкланды: туган халкының һәм җирле халыкның телен, мәдәниятен, әдәбиятын яхшы белгән, һәрьяктан камил, милли горурлык хисләре үскән шәхес (гражданин) тәрбияләү.

Әлеге максатны тормышка ашыру өчен, түбәндәге **бурычлар** билгеләнде:

− Татарстан төбәгендә яшәп, җирле халык белән аралашкан укучыларны төбәкнең әдәби-мәдәни байлыгы белән якыннан таныштыру;

− татар әдәбияты турындагы мәгълүматларны төрле халык фольклоры, әдәбияты, мәдәнияте, милли образлары белән чагыштырма-типологик аспектта бирү;

− татар халык авыз иҗаты турында тулы күзаллау булдыру, аны баланың үз туган халкының рухи җәүһәрләре белән чагыштырырга күнектерү;

− татар әдипләре, мәдәният әһелләре турында күзаллау булдыру, аларны танырга, аңларга, башка халык сүз сәнгатен үстерүчеләр белән чагыштырма планда бәяләргә өйрәтү;

− татар, рус, Россиядә яшәүче башка халыклар, бөтендөнья әдәбияты белеме казанышларының уртак нигезен аңлау, аларны үстерү һәм киңәйтү.

Әлеге максат һәм бурычларга ирешү өчен, түбәндәге принциплар истә тотылырга тиеш. Рус телендә сөйләшүче балалар өчен татар әдәбиятының асылын төшендерү укытучының сүз сәнгате серләрен яхшы белүен, иҗади эшләү күнекмәләре булуын таләп итә. Мәктәп баласына сүз сәнгатенең серләрен ачуда эстетик принцип (укытучының

матурлыкны күрә алуы һәм башкаларне да күрергә өйрәтә алуы), эзлеклелек (укучы алган белемнең тулыланып, баеп баруы), әдәбиятны сүз сәнгате буларак өйрәнү (татар телендә язылган әсәрләрдә әдәби образларны ачу үзенчәлекләре, татар теленең матурлыгын күрергә өйрәтү), күләме ягыннан кечкенә булган әсәрләргә шәхси мөнәсәбәт булдыру, ягъни психологик принцип (мәктәп баласының яшь үзенчәлекләрен, әдәби әзерлек дәрәҗәсен исәпкә алып эш итү) ярдәмгә килә. Аерым игътибар коммуникативлык принцибына бирелә. Бу принципның өстен чыгуы рус телендә сөйләшүче укучыларның әдәби әсәр аша татар теленең серләренә тирәнрәк төшенүләре, матур әдәбият әсәрен сорауларга нигезләнеп сөйли алуы, үз фикерләрен ачык әйтә алуы, әдәби әсәрнең аралашу чарасына әверелүе белән дә бәйле. Укучыларның әдәби әсәрне кабул итү һәм әдәби үсеш үзенчәлекләрен исәпкә алып, дифференциацияләү (аерым төркемнәргә аерып, бүлеп эшләү) һәм интеграцияләү (татар теле һәм рус әдәбияты дәресләрендә алынган теоретик белемнәрне һәм гамәли эш күнекмәләрен файдалану) дә үзәккә алына.

Төп мәктәп уку-укыту системасында 5 нче сыйныф әһәмиятле урын алып тора. Бу сыйныф балаларының яшь һәм әдәби үсеш үзенчәлекләрен исәпкә алып төзелгән УМК үз эченә дәреслекне, укучы өчен мөстәкыйль эш дәфтәрен, укытучылар өчен методик әсбапны ала.

Дәреслек ике кисәктән тора. Укучыларның белем-күнекмәләрен бәяләп бару өчен, һәр кисәк тә дүртәр модульгә бүлеп төзелгән. Һәр модуль бөтен кисәкнең өлешләрен хәтерләтә. Модульгә салынган мәгълүмат та, дәреслек үзе дә хронологик нигезгә корыла. Шул ук вакытта модульләр эчендә тематик-хронологик принцип та саклана.

Һәр модуль укучыларның әдәби үсеш дәрәҗәсен үстерүне дә, эрудициясен киңәйтүне дә, әдәбиятны сәнгатьнең башка төрләре белән бәйләп баруны да, теоретик төшенчәләрне үзләштерүне дә, сорау-биремнәрне үтәгәндә файдалана алуны да күздә тотып урнаштырылган. Дәреслектә модульләр арасындагы бәйләнешләр сорау-биремнәр һәм контроль тестлар аша гамәлгә куела. Шулай итеп, дәреслекне әдәби-теоетик төшенчәләр сүзлекчәсе, фразеологик сүзлекчә кебек белешмәләр төгәлләп куя.

**Уку елы бышына укучыларның гомуми белем һәм күнекмәләренә бәяләмә**

5”Б” сыйныфында төрле белемдәге укучылар укый. Гомумән алганда, укучылар зур күләмдә булмаган әдәби әсәрләрне укып, кыскача гына эчтәлеген әйтә алалар, диалоглар төзиләр, тәрҗемә итәләр. Программаны авыр үзләштерүче укучылар да бар. Алар килеш кушымчаларын, тартым кушымчаларын куллануда авырлык кичерәләр.

**Укыту - тематик планы**

| Эчтәлек | Сәгать саны |
|---|---|
| Борын-борын заманда... | 8 |
| Әкият яздым – укыгыз... | 5 |
| Хыял канатларында. | 5 |
| Белем баскычлары. | 7 |
| Балачак – хәтердә мәңге калачак... | 9 |
| Ватаным өчен. | 15 |
| Кояшлы ил – бәхет иле. | 9 |
| Кеше − табигать баласы. | 7 |
| Эш беткәч көләргә ярый. | 5 |
| Барысы: | 10 |

## II. Укыту предметының эчтәлеге

Борын-борын заманда.
Халык авыз иҗаты.
Фольклор әсәрләренең төрләре, жанрлары. Балалар фольклоры (бишек җырлары, табышмаклар, тизәйткечләр һ.б.).
Әдәбият теориясе. Фольклор. Халык авыз иҗаты.
Татар халык әкиятләре. Халык прозасының бер төре буларак әкиятләр. Әкиятләрнең хайваннар турында, тылсымлы, тормыш-көнкүреш төрләре булуы. Әкиятләргә салынган мәгънә, аларның әкият төзәтүгә юнәлдерелгән булуы, фәлсәфәсе.
«Ак бүре» (татар халык әкияте). Әкияттә яхшылык белән явызлык көрәше. Әкияттә халык морале, тылсым элементлары. Ак бүренең төрки халыкларның тотемы булуы. Әкияттәге традицион образлар. Тылсымлы әкиятләрнең поэтикасы. Тылсымлы әкияттә фантастика.
Татар халык әкияте «Абзар ясаучы төлке», «Өч кыз». Әкият геройлары, аларга хас сыйфатлар.
Әдәбият теориясе. Әкият. Әкият төрләре.. Әкият яздым укыгыз...
Халык әкиятләреннән үсеп чыккан автор әкиятләре турында мәгълүмат
Каюм Насыйри. Тормыш юлы турында мәгълүмат.
«Патша белән карт» әкияте. Әкияттә ил белән идарә итүче образы. Халыкның бер вәкиле булган тапкыр карт образы, аның зирзклеге.
Габдулла Тукай. Әдип турында мәгълүмат.
«Су анасы» әкият-поэмасы. Г.Тукай әкиятләренә иллюстрацияләр авторы – Байназар Әлменов.
Әдәбият теориясе. Әкият-поэма төшенчәсе.
Туфан Миңнуллинның «Гафият турында әкият» әкият-пьесасы. Әдәбият теориясе. Әкият-пьеса төшенчәсе.
«Әкият» курчак театры турында мәгълүмат. Театрлар тарихында курчак театрларының урыны, әһәмияте. Казандагы «Әкият» курчак театрының бинасы, репертуары, җитәкчелеге, режессёрлары, актёрлары.
Хыял канатларында.
Адлер Тимергалин «Сәер планетада». Адлер Тимергалин турында белешмә. Әсәрдәге фантастик алымнар.
Теоретик төшенчә. Фантастика. Фантастик элементлар.
Белем баскычлары.
Белемгә омтылу. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе турында мәгълүмат. Мәдрәсәнең 1882 нче елда Казанда ачылуы. Анда белем алучыларның шәкертләр дип аталуы.
Казанның Татар укытучылар мәктәбе турында мәгълүмат. Аның 1876 нчы елда ачылуы. Дүрт ел дәвамында белем алган укучыларның рус теле укытучысы булып китүе. Аларны Василй Радлов, Василий Богородицкий, Каюм Насыйри укытуы.
Казан университеты турында мәгълүмат. Аның 1804 нче елның 17 нче ноябрендә ачылуы. Анда Карл Фукс, Илья Березин, Николай Лобачевский эшләве. Анда белем алган атаклы кешеләр. Хәзер аның Казан (Идел буе) федераль университеты дип аталуы.
Гаяз Исхакыйның «Мөгаллим» пьесасы. Гаяз Исхакый турында мәгълүмат. «Мөгаллим» пьесасындагы Салих образы. Аңа салынган автор идеалы.
Дәрдемәннең «Кил, өйрән...» шигыре. Дәрдемәнд турында мәгълүмат. «Кил, өйрән...» шигыренә бәйләп телләр белүнең әһәмияте турында сөйләшү.
Балачак — хәтерләрдә мәңге калачак...
Габдулла Тукайның «Исемдә калганнар» әсәреннән өзек. Әсәрдә кечкенә Тукай образының бирелүе. Автобиографик әсәр герое белән Тукай арасында уртак һәм аермалы яклар. Кечкенә Габдулланың Хаҗиморат Казаковның «Бәләкәй Апуш» картинасында сурәтләнеше.
Габдулла Тукайның Кырлайдагы музее. Музей урнашкан төбәк. Андагы истәлекле экспонатлар.
Теоретик мәгълүмат. Мемориаль комплекс.

«Салават күпере» журналы. Аның тарихы һәм бүгенгесе турында мәгълүмат.
Ватаным өчен.
Гадел Кутуйның «Рөстәм маҗаралары» повестеннан «Әби әкияте», «Яз җиткәч», «Сихерле чәчәкләр», «Расад» бүлекләрен уку. Рөстәм образы турында сөйләшү. Малайга хас сыйфатларны табу. Хыял белән чынбарлык арасындагы аерманы табарга өйрәнү.
Муса Җәлилнең «Сагыну», «Соңгы җыр» шигырьләрен уку. «Алтынчәч»либреттосыннан өзек өйрәнү. Нәҗип Җиһановның либреттога музыка язуы. Композиторның иҗаты.
Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры турында мәгълүмат.
Фатих Кәримнең «Кыр казы», «Сөйләр сүзләр бик күп алар...» шигырьләрен уку. Аларда Туган илне саклау, ярату хисләренең салынган булуы.
Шәүкәт Галиевның «Аталы-уллы солдатлар» балладасы. Илне басып алучыларга көрәштә халыкның фидәкарьлеге. Ил батырларына хөрмәт.
Теоретик төшенчә. Баллада.
II бүлек. Кояшлы ил – бәхет иле.
Нәби Дәүлинең «Бәхет кайда була?» «Мин җирдә калам»шигырьләрендә бәхет эзләү һәм табу кебек фәлсәфи мәсьәләнең чишелеше. Лирик герой өчен бәхетнең үзе яшәгән җирдә булуы.
Фатих Хөснинең «Чыбыркы» хикәясе. Автор турында белешмә. Хикәядә малайның үз эшләре өчен җавап бирүе.
Теоретик төшенчә.Сюжет. Сюжет элементлары (экспозиция, төеноәнеш, вакыйгалар үстерелеше, кульминация, чишелеш)
Әхмәт Рәшитовның « Каяшлы ил – бәхет иле» шигыре. Туган ил кадерен белергә өйрәтү. Лирик геройның кичерешләрен ачу.
Кеше – табигать баласы.
Равил Фәйзуллинның «Табигать кочагында» шигыре. Шигырьдә табигатьне саклау, аны ярату хисләре өстенлек итүен ачыклау.
Мөдәррис Әгъләмовның «Матурлык минем белән» шигыре, «Җир-ана, кояш һәм башкалар» балладасы. Матурлыкны табигатьтән эзләү мотивы. Табигатьнең кешеләргә мәрхәмәтле булуы, аны сакларга кирәклеген төшендерү.
Рәссам Иван Иванович Шишкин иҗаты. Аның Татарстан белән бәйле язмышы. Иҗаты.
IV бүлек. Эш беткәч көләргә ярый.
Ләбиб Леронның «Пирамида» хикәясе. Укучыларда белем алуга теләк тудыру. Укымыйча гына белемле булып булмавын ачыклау.
Теоретик төшенчә. Юмор.
Алмаз Гыймадиевның «Зөлфия + ... мин» хикәясе. Яшүсмерләрне беренче мәхәббәт хисләренең сурәтләнеше. Язуда гына түгел, тормышта да хаталар җибәрергә ярамавын ачыклау.
Шәүкәт Галиевның «Ул кем?» «Әлләкем», «Мәрзия мәсьәләсе» шигырьләре. Шагыйрьнең табышмак, юмористик -шигырьләрендә бала хисләренең ачылышы.

**.5 нче сыйныф укучыларының әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр**

– әдәби әсәрләрне сүзләрен дөрес әйтеп йөгерек уку;
– авторның әйтергә теләгән фикерен аңлау, үз мөнәсәбәтен белдерү, өлешләргә бүлә һәм планын төзи белү;
– әдәби − теоретик төшенчәләрне рус әдәбият белеме белән тәңгәлләштерү;
– татар әдәбиятының дөнья культурасында тоткан урынын аңлау;
– авторларның тормыш юлы һәм иҗаты турында кыскача күзаллау;
– 8 − 10 татар, рус, чит ил язучысы, шагыйрьләре исемнәрен һәм алар язган әсәрләрне белү;
– 3 − 4 сәнгать әһеленең тормышы, иҗатын турында мәгълүматлы булу;
– Казан һәм Татарстан төбәгендәге мәдәният учаклары (музей, театр, концерт залы, һ. б.), балалар матбугаты турында белү;

– төрле халыкларның фольклор үрнәкләрен татар халык авыз иҗаты белән чагыштыру;

– төрле халыкларның киң таралган мифларыннан хәбәрдар булу, берничә мисал китерә белү;

– 5 мәкаль, 5 әйтемне русча эквивалентлары белән истә калдыру;

– мәкаль белән әйтем, миф белән әкият, халык җыры белән автор җыры арасындагы аерманы белү;

– төрле авторларның 2 − 3 шигырен яттан сөйли белү;

– сүзлекләр, энциклопедияләр, Интернет-ресурслардан файдаланып, үзенә кирәкле материалны табу;

– төрле темаларга проект эше яклау;

– әдәби әсәргә тормыш белән бәйләп, үз гамәлләренә бәя бирү.

## III. Татар телеһәм әдәби укудан календарь-тематик планлаштыру

| № | Дәрес темасы | Укучылар эшчәнлеге төрләре | Үткәрү вакыты |
|---|---|---|---|
| 1 | Акыллы сүзгә ни җитә! | «Халык авыз иҗаты» схемасы белән эш, дәреслектә, эш дәфтәрендә биремнәр, рус халык авыз иҗаты белән чагыштырып, мисаллар китерү. | 1.09 |
| 2 | Белмәгән-гә — әкият, белгәнгә — чын. | «Әкиятләр» схемасы белән эш, дәреслек, эш дәфтәрендә биремнәр эшләү, чылбыр буенча уку, чылбыр буенча сөйләү, җөмләләр төзү. | 6.09 |
| 3 | Яхшылыкка каршы яхшылык. | Әкиятне укып чыгу һәм терәк сораулар буенча анализлау, гомумиләштереп, нәтиҗәләр чыгару. | 8.09 |
| 4 | Яхшылыкка каршы яхшылык. | Әкиятне укып чыгу һәм терәк сораулар буенча анализлау, гомумиләштереп, нәтиҗәләр чыгару. | 13.09 |
| 5 | Булма син төлке, булырсың көлке | Әкияттәге уңай һәм тискәре образларны табу, аларга хас сыйфатларны билгели белү | 15.09 |
| 6 | Булма син төлке, булырсың көлке. | Әкияттәге уңай һәм тискәре образларны табу, аларга хас сыйфатларны билгели белү. | 20.09 |
| 7 | Ана дигән хәзинә. | Дәреслектә, эш дәфтәрендә биремнәр эшләп, әкиятнең эчтәлегенә төшенү, геройларга бәяләмә бирү. | 22.09 |
| 8 | Борын-борын заманда... Тест эшләү. (Кабатлау дәресе) | Бәйләнешле сөйләм телен үстерү, белемнәрне тикшерү. | 27.09 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 9 | Яшәгән, ди, булган, ди... | Әңгәмә, сәнгатьле уку. Бирелгән билгеләмәләргә нигезләнеп, нәтиҗә ясау. Үз фикереңне әйтә белергә өйрәнү. | 29.09 |
| 10 | Юк дип әйтмә, бардыр ул... | Әкиятне уку, дәреслек, эш дәфтәрендә биремнәр эшләү, әкият-поэмада әкияткә хас сыйфатларны табу. | 4.10 |
| 11 | Б.Әлменов. «Су анасы» картинасы. | Рәсемне аңлау, төп детальләргә игътибар итеп, аның эчтәлеген сөйләтү, нәтиҗә ясау. | 6.10 |
| 12 | Әкиятче бездә кунакта. | Әкият-пьесаны сәнгатьле итеп уку, аңлаганны сораулар ярдәмендә тикшерү, анализлау. | 11.10 |
| 13 | Әкияттә кунакта. | Яңа материал белән танышу, укытучының кереш сүзе, укылган текст буенча фикер алышу. | 13.10 |
| 14 | Әкият тә түгел, чын да түгел. | Хикәяне уку, сүзләрне аңлату, сораулар буенча төп фикерне табу, нәтиҗә ясау. | 18.10 |
| 15 | Әкият тә түгел, чын да түгел | Хикәяне уку, сүзләрне аңлату, сораулар буенча төп фикерне табу, нәтиҗә ясау. | 20.10 |
| 16 | Хыял дөньясын-да. | Сайлап алып уку, укыганны анализлый белү, үз фикереңне тексттан дәлилләр табып исбатларга өйрәнү, белемнәрне тикшерү. | 25.10 |
| 17 | Кабатлау дәресе. Хыял дөньясын-да. | Сайлап 9лы пуку, укыганны анализлый белү, үз фикереңне тексттан дәлилләр табып исбатларга өйрәнү, белемнәрне тикшерү. | 27.10 |
| 18 | Дәрес- | Укучылар үзләре уйлап язган яки | 8.11 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | проект. | башка авторларныкы булган, тәрҗемә иткән әкият һәм фантастик әсәрләрне китапчык итеп, рәсемнәр белән бизәп, сыйныфташларына тәкъдим итәләр. | |
| 19 | Белем — бәхет ачкычы. | Уку, эчтәлеге буенча фикер алышу, мәкальләр уку, рәсемнәр күзәтү. Төрле биремнәр эшләү. | 10.11 |
| 20 | Белем укудан башлана. | Китаптагы текст белән  танышу, уку, укытучының истәлекләр белән таныштыруы. | 15.11 |
| 21 | Укытучылар мәктәбе. | Тема буенча укытучының кереш сүзе, текстны укып, әңгәмә оештыру. | 17.11 |
| 22 | Казан университеты. | Текст җөмләләрен кыс-картып әйтү, анализ ясау. | 22.11 |
| 23 | Галим кеше хөрмәткә лаек! | Әсәрне аңлату, сөйләү, әңгәмә, сорау кую, нәтиҗәләр чыгару. | 24.11 |
| 24 | Кил, өйрән… | Текстның эчтәлеген аңлап, үз фикереңне әйтә белү. | 29.11 |
| 25 | Укысаң – белерсең… | Сайлап 10лы пуку, укыганны анализлый белү, үз фикереңне тексттан дәлилләр табып исбатларга өйрәнү, белемнәрне тикшерү. | 1.12 |
| 26 | Исемдә калганнар. | Әңгәмә, сөйләү, образларга бәяләмә, сүзлек эше, анализ, биремнәр эшләү. | 6.12 |
| 27 | Исемдә калганнар | Әңгәмә, сөйләү, образларга бәяләмә, сүзлек эше, анализ, биремнәр эшләү. | 8.12 |
| 28 | Исемдә калганнар | Әңгәмә, сөйләү, образларга бәяләмә, сүзлек эше, анализ, биремнәр эшләү. | 13.12 |
| 29 | Исемдә | Әңгәмә, сөйләү, образларга | 15.12 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | калганнар | бәяләмә, сүзлек эше, анализ, биремнәр эшләү. | |
| 30 | Бөек Тукай һәм Бәләкәй Апуш. | Рәсемне аңлау, төп детальләргә игътибар итеп, аның эчтәлеген сөйләтү, нәтиҗә ясау. | 20.12 |
| 31 | Музейларда — хәтер. | Тукай музее белән танышу. Видео, презентацияләр карау. | 22.12 |
| 32 | Кабатлау дәресе. Ямьле балачак. | Укыганнарны искә төшереп, гомумиләштереп кабатлау. Тексттан мисаллар китереп, теорияне искә төшерү. Белемнәрне тикшерү. | 10.01 |
| 33 | «Салават күпере» журналы. | Хикәя төзү, диалогик сөйләм күнекмәләрен үстерү. | 12.01 |
| 34 | Проект-дәрес «Салават күпере — дуслык күпере». | Командалап эшләү, рубрикаларны укып, фикер алышу, булган материалдан кирәклесен сайлап алып эшкәртү, эшне аудиториягә тәкъдим итү. | 17.01 |
| 35 | «Әгәр мин тылсымчы булсам...» | Фантастик хикәяләүне аңлап, әсәрне аңлау, сугыш чоры, партизаннар турында белү, сүзләрне тәрҗемә итеп, мәгънәләренә төшенү. | 19.01 |
| 36 | «Әгәр мин тылсымчы булсам...» | | 24.01 |
| 37 | «Әгәр мин тылсымчы булсам...» | | 26.01 |
| 38 | «Әгәр мин тылсымчы булсам...» | | 31.01 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 39 | Мин сине шундый сагындым... | Язучы иҗаты белән танышу, әсәрне укып, укытучы җитәкчелегендә бергәләп анализлау, нәтиҗә ясау. | 2.02 |
| 40 | Гомере аның моңлы бер җыр иде... | Шигырьне уку, сорау-биремнәргә җавап эзләү. | 7.02 |
| 41 | «Алтын чәч». | Эчтәлек белән танышу, әсәрнең төп фикерен аңлату, эш дәфтәрендә биремнәр эшләү, чылбыр буенча уку. | 9.02 |
| 42 | «Алтын чәч». | Эчтәлек белән танышу, әсәрнең төп фикерен аңлату, эш дәфтәрендә биремнәр эшләү, чылбыр буенча уку. | 14.02 |
| 43 | Опера ничек туа? | Тема белән кызыксынып, уйны ачык итеп әйтү. | 16.02 |
| 44 | Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры. | Эчтәлек белән танышу, әсәрнең төп фикерен аңлату, эш дәфтәрендә биремнәр, чылбыр буенча уку, диалогик сөйләм үстерү. | 21.02 |
| 45 | Кыр казы | Сәнгатьле уку, дәреслек, эш дәфтәрендә биремнәр аша лирик әсәрне анализлау. | 23.02 |
| 46 | Сөйләр сүзләр бик күп алар... | Сәнгатьле уку өстендә эшләү, әңгәмә, сорауларга җавап бирү. | 28.02 |
| 47 | Аталы-уллы солдатлар. | Уку, рәсемнәр буенча әсәрнең эчтәлеген сөйләү, фикерне ачу. | 2.03 |
| 48 | Кабатлау дәресе. Сугыш кайтавазы. | Бәйләнешле сөйләм телен үстерү, нәтиҗәләр чыгару, анализ ясау, белемнәрне тикшерү. | 7.03 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | |
| 49 | Дәрес-проект «Беркем дә, бернәрсә дә онытылмый...» | Командалап эшләү, китапчыклар, буклетлар яки плакатлар ясау, аларны тәкъдим итү. | 9.03 |
| 50 | «Бәхет кайда була?» | Язучы иҗатына күзәтү ясау, әсәрен укып, ярдәмче сорауларга нигезләнеп, аңа бәя бирү. | 14.03 |
| 51 | «Бәхет кайда була?» | Язучы иҗатына күзәтү ясау, әсәрен укып, ярдәмче сорауларга нигезләнеп, аңа бәя бирү. | 16.03 |
| 52 | Туган җирдә минем бәхетем. | Уку, сораулар, биремнәр ярдәмендә эчтәлеген аңлау, әсәр буенча фикер алышу. | 30.03 |
| 53 | Минем холкым — минем язмышым. | Әсәрне өлешләргә бүлү. Эчтәлекнең идеясен таба белү. Исем табу — тема — идея — эчтәлек бәйләнешләрен табу, анализлау. | 4.04 |
| 54 | Минем холкым — минем язмышым. | Эчтәлекнең идеясен таба белү. | 6.04 |
| 55 | Минем холкым — минем язмышым. | Исем табу — тема — идея — эчтәлек | 11.04 |
| 56 | Минем холкым — минем язмышым. | Исем табу — тема — идея — эчтәлек бәйләнешләрен табу, анализлау. | 13.04 |
| 57 | Минем холкым — минем язмышым. | Анализлау, Фикер алышу | 18.04 |
| 58 | Кабатлау дәресе. Кояшлы ил | Бәйләнешле сөйләм телен үстерү, нәтиҗәләр чыгару, анализ ясау, җыр өйрәнү, белемнәрне тикшерү. | 20.04 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | — бәхет иле. | | |
| 59 | Табигать кочагында. | Уку, әңгәмә, биремнәрне үтәү, рәсем ясау. | 25.04 |
| 60 | Матурлык минем белән. | Уку, сорауларга җавап бирү. Хикәя буенча фикер алышу. | 27.04 |
| 61 | Матурлык минем белән | Хикәя буенча фикер алышу | 2.05 |
| 62 | Җир-ана, кояш һәм башкалар. | Сүзлек өстендә эш, эчтәлек буенча фикер алышу. | 4.05 |
| 63 | Җир-ана-быз — рәсем-нәрдә. | Бәйләнешле сөйләм телен үстерү, нәтиҗәләр чыгару, анализ ясау. | 9.05 |
| 64 | Кабатлау дәресе. Туган илем — иркә гөлем. Тест | Бәйләнешле сөйләм телен үстерү, нәтиҗәләр чыгару, анализ ясау, белемнәрне тикшерү. | 11.05 |
| 65 | Дәрес-проект «Гүзәл табигатьле туган җирем». | Бәйләнешле сөйләм телен үстерү, нәтиҗәләр чыгару, анализ ясау. | 16.05 |
| 66 | Белем — нур, белмәү — хур. | Текстны уку, сүзлек эше, рәсем буенча сөйләшү, биремнәр эшләү, сорауларга җавап бирү. | 18.05 |
| 67 | Беренче хисләр... | Дәреслек, эш дәфтәрендә биремнәрне эшләп, хикәянең эчтәлегенә төшенү, геройларга бәяләмә бирү. | 23.05 |
| 68 | Шәвәли шуклыгы. | Шигырьне укып, сорау-лар буенча анализлау, нәтиҗәләр ясау. | 25.05 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | |
| 69 | Кабатлау дәресе. Уйныйк та көлик! | Бәйләнешле сөйләм телен үстерү, нәтиҗәләр чыгару, анализ ясау, белемнәрне тикшерү. | 30.05 |
| 70 | Йомгаклау дәресе. | Анализ ясау, белемнәрне тикшерү. | 31.05 |

Пронумеровано,прошнуровано

14 (четырнадцать)

Учитель татарского языка и литературы

Чибинова Лилия Раисовна